**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2024 елның 22 октябре                                        1892 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлеген торглар үткәрмичә түләү белән арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июлендәге 1984 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 22 июлендәге 194-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлеген торглар үткәрмичә түләү белән арендага, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июлендәге 1984 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

1) 2.8.2.1 пунктының 9-10 пунктчасы:

– 9 пунктчада «территорияне, яисә» сүзләрен ««территорияне яисә, күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплексслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, аны комплексслы үстерү турында карар кабул ителсә, яисә» сүзләренә алмаштырырга;

– 10 пунктчада "территориясен, һәм" сүзләрен "территориясен, йә әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплексслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, аны комплексслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, һәм"..

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э. В. Хисмәтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**